ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.12.2024 п.г.т.Алексеевское № 605

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Башкарма комитетының**
**23.12.2022 ел, № 567 «Инфраструктура**
**үсеше бүлеге тарафыннан**
**муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең**
**административ регламентларын**
**раслау турында» карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 23.12.2022 ел, № 567 «Инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1-3 нче кушымталарның 3.3.2.1 пунктының 11 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Төзелгән гарызнамәне формат-логик тикшерү орган (оешма) билгели торган таләпләр нигезендә, мөрәҗәгать итүче гарызнамәнең электрон рәвешендәге һәр кырын тутырган вакытта, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал сорауның электрон рәвешендәге дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, мөрәҗәгать итүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында турыдан-туры сорауның электрон рәвешендәге мәгълүмати хәбәр аша хәбәр ителә.»;

1.2. 1-3 нче кушымталарның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм башкару сроклары, аларны башкару тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ

процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре»;

1.3. 1-3 нче кушымталарда 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган хезмәтләрне күрсәтүдә катнашучы экспертлар тарафыннан күрсәтелә,раслана:

1) җирле үзидарәнең вәкиллекле органының норматив хокукый акты белән-җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтү максатларында күрсәтелә торган хезмәтләргә карата.»;

1.4. 1-3 нче кушымталарның 2.5.1 пунктындагы «1» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

1) шәхесне таныклаучы документ (Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтына http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Р.С. Язынинга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **О.Н. Леденцов**